Tatar16.ru

# Афзал Шамов

(1901 – 1990)

*« Сатмас егет илен алтын көмешләргә,*
*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*
*Алтынны ул чүпкә санар,*
*Иң кыйммәтле күрер Ватанын »*





Tatar16.ru

- Афзал Шамов, тулы исеме Афзалетдин Шиһабетдин улы Шамов (1901 елның 4 марты — 1990 елның 19 гыйнвары) — танылган татар язучысы, тәрҗемәче, Татарстан Язучылар берлеге рәисе.
- Язучы 1901 елның 4 мартында элекке Казан

- Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстанның Яшел Үзән районы) Татар Танаеавылында хәлле крестьян гаиләсендә туган. Мәктәп чорында аны шул чорның күренекле педагогы Фатих Сәйфи-Уфалы укыта һәм кечкенә Афзалда әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли.
- Казанның Касыймия мәдрәсәсендә белем алган Афзал Шамов 1922-1925 елларда Казан дәүләт

Tatar16.ru



Tatar16.ru



- университетырабфагында укый. 1926 елдаБеренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультетына укырга керә, беррәттән РСФСР Мәгариф комиссариаты каршындагы Төрки халыклар бүлегенең укый-яза белмәүне бетерү комиссиясе әгъзасы

Tatar16.ru

- вазыйфасын башкара.
- Афзал Шамов — татар әдәбиятында, иң беренче чиратта, оригиналь проза әсәрләре: хикәяләр һәм повестьлар авторы буларак танылган язучы. Аның егерменче еллар татар авылы тормышына багышланган "Рәүфә" (1926), гражданнар сугышы чоры героикасына бәйле "Днепр буенда" (1927), "Бер мәхәббәт турында" (1933), совет тормышы шартларында гаилә кору һәм
- башка әхлакый мәсьәләләрне яктырткан "Ана" (1933), "Госпитальдә" (1938), "Туйда" (1938) кебек повесть һәм хикәяләре егерменче-утызынчы еллардагы татар әдәбиятының сәнгатьчә югары дәрәҗәдә эшләнгән матур үрнәкләре булып саналалар. Ул язган хикәяләр рус, венгер, казак, чуаш, башкорт һәм башка

Tatar16.ru



- *телләргә тәрҗемә ителәләр.*
- *Афзал Шамов — әдәби тәрҗемә остасы. Мәсәлән, Александр Пушкинның"Капитанская дочка" ("Капитан кызы", 1936), Николай Гогольнең"Старосветские помещики" ("Борынгы алпавытлар", 1939), Николай Островскийның "Как*

- закалялась сталь" ("Корыч ничек чыныкты", 1936), Жюль Вернның "Дети капитана Гранта" ("Капитан Грант балалары", 1938), Лев Толстойның "Воскресение" ("Яңадан туу", 1950) романы белән "Хаҗи Морат" (1953) повесте һ.б. бар.
- Бөек Ватан сугышы чорындагы шәхси батырлыклары һәм әдәби иҗат өлкәсендәге хезмәтләре өчен А. Шамов Кызыл Йолдыз (1944), Хезмәт Кызыл Байрагы
- (1957), Октябрь Революциясе (1971) орденнары һәм уннан артык медаль белән бүләкләнгән.
- Афзалетдин Шамов 1990 елның 19 гыйнварында вафат була.

Tatar16.ru